КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2021 ел, 13 сентябрь г.Казань № б-1822

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 24 июнь, б-1038 нче боерыгы белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 17 гыйнвар, б-58 нче; 2014 ел, 25 июль, б-1427 нче; 2014 ел, 12 декабрь, б-2579 нчы; 2015 ел, 13 гыйнвар, б-5 нче; 2015 ел, 12 март, б-390 нчы; 2015 ел, 5 сентябрь, б-2002 нче; 2016 ел, 26 апрель, б-709 нчы; 2016 ел, 28 июль, б-1601 нче; 2016 ел, 10 сентябрь, б-2000 нче; 2017 ел, 22 февраль, б-326 нчы; 2017 ел, 31 март, б-599 нчы; 2017 ел, 5 август, б-1895 нче; 2018 ел, 30 гыйнвар, б-180 нче; 2018 ел, 10 декабрь, б-3357 нче; 2019 ел, 20 февраль, б-347 нче; 2019 ел, 28 декабрь, б-3529 нчы; 2020 ел, 18 май, б-974 нче боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган төзелешкә рөхсәтнамәләр алуны таләп итми торган очраклар исемлегенә, түбәндәге эчтәлекле 11 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«11) федераль, һәм (яки) республика, һәм (яки) инвестиция программаларын тормышка ашыру кысаларында крестьян (фермер) хуҗалыгы һәм (яки) юридик зат – авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре мөлкәте составына керә торган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясенә кертелгән җир кишәрлекләрендә гамәлгә ашырыла торган җир асты үткәргеченең мелиорация системаларын, аларга технологик бәйле булган җиһазларны һәм корылмаларны төзү һәм (яки) реконструкцияләү.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин